АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423740, село Актаныш,
проспект Ленина, дом 58
тел 3-44-40

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423740, Актаныш авылы,
Ленин проспекты, 58 йорт
Тел 3-44-40

**КАРАР**

№ 17 «10» декабрь 2020 ел

Салют уткәрү урыннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 313-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 ноябрендәге 1062 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында "Карарын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү хакында»

**КАРАР** бирәм:

**1**.Махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда куркынычлык класслы пиротехник эшләнмәләрне (бенгаль утларыннан, мамыклардан тыш) чикләрдә урнашкан территорияләрдә кулланууны тыю билгеләргә:

- торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары, кешеләр күплэп була торган объектлар, автомобиль юллары чикләреннән 50 метр ераклыкта.

**2.**Пиротехник эшләнмәләр кулланып салют уткәрү өчен, социаль өлкәдәге якын-тирә торак объектларына кадәр билгеләнгән таләпләргә туры килә торган ераклыкта урыннар (мәйданчыклар) билгеләргә:
а) Актаныш авылы Җиңү паркында;
б)Татарстан Республикасы «Агыйдел" Дәүләт җыр һәм бию ансамбле бинасы каршындагы мәйданда.

**3**.Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда яннарында пиротехник эшләнмәләрне куллану тыелган объектлар исемлеген № 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**4.** Яңа ел салюты уткәрүне оештыручылар административ законнар нигезендә җаваплы.

**5.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Актаныш авыл Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Шәрипов

АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

Актаныш муниципаль районы
Актаныш авыл Башкарма комитетының
2020 елның 10 декабре №17 карарына
кушымта № 1

Янәшәсендә махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда пиротехник эшләнмәләрне куллану тыелган объектлар исемлеге.

**1.** Ягулык-энергетика комплексының линия объектлары: электр челтәрләре, магистраль газүткәргечләр.

**2.** Торак-коммуналь хуҗалык объектлары: торак фонд, оешма, газ, җылылык, электр белән тәэмин итү объектлары.

**3.** Авыл хуҗалыгы объектлары: терлекләр асраучы хуҗалыклар(сыер абзарлары, ат абзарлары); ашлык саклау урыннары; агулы химикатлар һәм минераль ашламалар саклау складлары; ремонт, технологик хезмәт күрсәтү һәм саклау буенча гаражлар һәм парклар;

**4.** Халык күп була торган объектлар: дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының административ бинаалары, мәдәният, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау объектлары.